РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТА РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

13.05.2026 №178/Бк/к

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасында Россия хәрби – тарихи җәмгыяте региональ бүлекчәсенең җирле бүлекчәсен төзү турында» 2022 елның 20 июнендәге 162/Бк/к номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021елның 02 декабрендәге 03-54/15918 номерлы хаты үтәлешендә һәм тарихи-мәдәни мирас объектларына, яшь буын тарафыннан патриотизм һәм илебезнең үткәненә сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү мәсьәләләренә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү, «Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасы эшчәнлеген популярлаштыру максатларында, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты, карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасында Россия хәрби – тарихи җәмгыяте региональ бүлекчәсенең җирле бүлекчәсен төзү турында» 2022 елның 20 июнендәге 162/Бк/к номерлы карарына түбәндәге өстәмәләрне һәм үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) белешмәләре Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турындагы законнарда каралган контрольдә тотылучы затлар реестрына кертелгән чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат;».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә. http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль башкарма комитетының яшьләр эшләре бүлеге башлыгына йөкләргә.

Буа муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе Л. Р. Шакирҗанов